ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.09.2019 г.Мензелинск № 842

Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында

1. Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәне расларга (Кушымта №1).
2. Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составын расларга.
3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче урынбасары А.Г. Гатина

Минзәлә муниципаль районының
Башкарма комитеты карарына
Кушымта № 1
№ 842 дата 03.09.2019

Ирektән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының (шәһәр округы) ирektән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссиясе (алга таба – Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының (шәһәр округы) җирле үзидарә органнарының, башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән ирektән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны кабаттан социальләштерү мәсьәләләре буенча үзара бәйләнешне оештыру һәм эшчәнлекне координацияләүне тәэмин итүче Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы каршындагы даими эшләүче координацион орган булып тора.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының (шәһәр округы) муниципаль хокукый актларын, шулай ук ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны кабаттан социальләштерүгә ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы Нигезләмәне кулланып эш итә.

1.3. Ведомствоара комиссиянең эшчәнлеге кабаттан социальләштерүдә ярдәм күрсәтү күздә тотылган затларның ирekлелеге һәм теләген белдерү ирege принципларына нигезләнә.

## II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Минзәлә муниципаль районында (шәһәр округында) ирektән мәхрүм ителү рәвешендә җинаять җәзасын үтәгән һәм (яисә) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар ителгән затларны җәмгыятькә кабаттан интеграцияләү максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

постпенитенциар озату;

профессиональ ориентлашу һәм хезмәт аша адаптация;

торак һәм көнкүрештә урнашу;

медицина озатуы;

психологик ярдәм;

җуелган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне кабаттан торгызуда ярдәм күрсәтү;

иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерүнең башка формалары.

2.2. Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны кабаттан социальләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән үзара аралашуын һәм эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабаттан (рецидив) җинаятчелекне булдырмау.

2.5. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) территориясендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны хезмәт аша интеграцияләү һәм кабаттан социальләштерү буенча уздырылучы эш турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү.

## III. Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләре

Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатыннан түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Кабаттан социальләшүдә ярдәм күрсәтүгә ризалык биргән затларның социаль хәлен анализлый һәм шәхси тәртиптә тикшерә

3.2. Дәүләт һәм муниципаль ярдәмнең законда каралган механизмнарын, башка оешмаларның һәм гражданлык җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны кабаттан социальләштерүнең шәхси программасын әзерли. Тернәкләндерү программасында каралган чараларның һәркайсын гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны, аларны гамәлгә ашыру срокларын билгели.

3.3. Нәтиҗәләрне һәм кабаттан социальләштерү буенча уздырылган чараларның нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4. Түбәндәге очракларда кабаттан социальләштерү шәхси программасын гамәлгә ашыруны туктату турында карар кабул итә: тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешкәндә;

Затның Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) чикләреннән чыгып китүе (әгәр зат Татарстан Республикасы чикләрендә башка муниципаль районга (шәһәр округы) чыгып киткән очракта, әлеге затка

карата булган материаллар белән бергә күрсәтелгән факт турында мәгълүмат Татарстан Республикасының күрсәтелгән районнның (шәһәр округы) ведомствоара комиссиясенә җибәрелә);

кабаттан социальләшүдә ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында затның гаризасы керүе;

кабаттан социальләшүнең шәхси программасын алга таба гамәлгә ашыру мөмкинлегенә юл куймаучы башка очракларда.

3.5. Минзәлә муниципаль районында (шәһәр округы) кабаттан (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.6.1. Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм гражданлык җәмгыяте институтлары тарафыннан башкарылырга тәкъдим ителгән карарларны үз компетенциясе чикләрендә кабул итәргә;

3.6.2. Җинаять һәм административ җаваплылыкка китерүче законны бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документларны җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе чикләрендә үзара аралаша:

3.7.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү Федераль хезмәте Идарәсе белән;

3.7.2. Түбәндәге мәсьәләләр буенча эчке эшләр органнары белән:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

шәхси профилактик эш уздыру;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

3.7.3. Татарстан Республикасының Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан (социаль яклау бүлекләре, мәшгульлек үзәкләре, халыкка социаль ярдәм күрсәтү учрежениеләре) түбәндәге мәсьәләләр буенча:

1999 елның 17 июлендәге “Дәүләт социаль ярдәме турында”гы №178-ФЗ Федераль законы һәм татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.09.2014 елдагы “Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү, шул исәптән, Татарстан Республикасында социаль контракт нигезендә” №635 карарына гамәлгә ашыру кысаларында, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр алучылар белән билгеле яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә профилактик эш;

иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаганнарга социаль адаптация уздыру, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә иректән мәхрүм итү белән бәйләнмәгән җәзаларга тартылган балигъ булмаган гражданнар;

иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителүче затларга хезмәт

базары, вакансияләр турында мәгълүмат бирү юлы белән кабаттан социальләшүгә ярдәм итү;

иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, күрсәтелгән категориядәге затларга эшчәнлек төрен (һөнәр) сайлау, эшкә урнаштыру, һөнәри белем бирү максатларында һөнәри ориентация буенча бушлай дәүләт хезмәтләрен күрсәтү – эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, хезмәт базарында эшсез гражданнарга социаль адаптация буенча, һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга туры килгән эш табуда ярдәм күрсәтү;

иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштырган эш бирүчеләргә стимул бирү;

3.7.4. Беренчел медицина-санитар ярдәмен, профилактик һәм дсипансер күзәтүне оештыру мәсьәләләре буенча сәламәтлек саклау учреждениеләре, сәламәтлек саклау территориаль идарәсе (булган очракта) тарафыннан;

3.7.5. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары , оешмалар, үз компетенцияләре нигезендә гражданлык җәмгыяте институтлары тарафыннан.

## IV. Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары составында формалаша.

Ведомствоара комиссия рәисе:

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә; хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, Ведомствоара комиссия утырышларын алып бара;

Ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

үз вәкаләтләре кысаларында Ведомствоара комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия кабул иткән документларны имзалый;

Ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен персональ җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия Сәркатибе:

Ведомствоара комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

Ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны , тиешле карарлар проектын әзерләү буенча эшне җайга сала, комиссия утырышы беркетмәләрен алып бара;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аңа чакырылган затларга Ведомствоара утырышның көн тәртибе, уздырылу урыны һәм вакыты турында мәгълүмат бирә , аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районының (шәһәр

округы) җирле үзидарә органнарына җәзаларны үтәтү системасы учреждениеләре хакимиятеннән затны тиздән азат итү, аның торагы булуы, хезмәткә яраклылыгы һәм булган белгечлекләре турында органнарга кергән мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

Ирektән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затлардан кабаттан социальләштерүдә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кабул итүне гамәлгә ашыра;

Программаның һәр катнашучысына кабаттан социальләштерү озату картасын һәм кабаттан социальләштерү индивидуаль программасының чараларын башкару буенча документлар һәм мәгълүматлар кертелгән личное делоны рәсмиләштерә.

Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан Ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматларны соратып ала;

Ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

Ведомствоара комиссия рәисенең йөкләмәләрен үтәүне, аның утырышлары нәтиҗәләре буенча мәгълүматларны үтәүне оештыра;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) халкына Ведомствоара комиссиянең функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссиянең составы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы күрсәтмәсе белән расланa.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының (шәһәр округы) җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, белем бирү оешмалары вәкилләре керергә мөмкин (килешенү буенча).

4.4. Ведомствоара комиссия составына кабаттан социальләштерүнең уңай тәҗрибәсе булган моңа кадәр ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Минзәлә районы (шәһәре) прокуратурасы вәкиле катнашырга хокуклы (килешенү буенча).

4.6. Ведомствоара комиссия утырышларына Ведомствоара комиссия составына кертелмәгән дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы (шәһәр округы) җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмаларның, гражданлык җәмгыяте институтларының һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу җәмәгать башлангычында гамәлгә ашырыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә гамәлгә ашырыла.
5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затлардан кабаттан социальләштерүдә ярдәм күрсәтү турында гаризалар керү белән уздырыла, әмма айга кимендә бер тапкыр булырга тиеш.

Зарурлык туган очракта Ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук Ведомствоара комиссия әгъзасы (рәис белән килешенү буенча һәм Ведомствоара комиссия сәркатибенең күрсәтмәсе буенча) инициативасы буенча Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырыш уздырылырга мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышларын Ведомствоара комиссия рәисе, ул булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча - Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары уздыра.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышларының вакыты һәм урыны турында кабаттан социальләштерүдә ярдәм күрсәтү турында гариза кергән затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашуы максатка ярашлы дип табылган башка затларга хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышларының вакыты һәм урыны турында Минзәлә районы (шәһәре) прокурорына хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы анда составның яртыдан артыгы катнашкан очракта тулы хокуклы булып санала.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерында һәм ачык тавыш бирү аша утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

5.8. Утырышта карала торган мәсьәләләрне тикшергәндә Ведомствоара комиссия әгъзалары тигез хокукка ия.

5.9. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затның теләге буенча, утырыш гамәлдәге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгәнчә, затларны чакырмыйча уздырыла.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары күрсәтелгән мәсьәләләр кагыла торган затларның ризалыгыннан башка комиссия утырышында каралган мәсьәләләр турында мәгълүматларны фаш итәргә хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны фаш иткән өчен Ведомствоара комиссия әгъзалары закон каршында җавап бирәләр.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында, Ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, персональ мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү мөмкин.

Минзәлә муниципаль районының
Башкарма комитеты карарына
Кушымта № 2
№842 дата 03.09.2019

Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составы

1. Бикеева Н.Г. – Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча Урынбасары – эшче төркем рәисе.
2. Ягафаров Р.Ф. – ТР Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе.
3.Мясникова Т.А. – Татарстан Республикасының Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Минзәлә районында социаль яклау бүлеге начальнигы (килешенү буенча).
4.Сәмигуллина Т.А. – Минзәлә районының “Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУ директоры (килешенү буенча).
5.Мөбәрәкшин Н.А. – “Минзәлә район үзәк хастаханәсе” ДАССУ баш табибы (килешенү буенча).
4. Хаҗиев И.М. – Минзәлә районы буенча ЭЭМ бүлеге начальнигы (килешенү буенча).
5. Нәҗмиев И.Ф. – Россия Җәзаларны үтәтү хезмәте Федераль идарәсе ФКУ ТРның Минзәлә районы буенча филиалы начальнигы